Татарстан Республикасы
Нурлат  муниципаль района
Әмзә авыл җирлеге Советы

КАРАР

«28» июль  2021 ел                                                                                № 20

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2008 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Советының сәламәтлек саклау, санитария һәм экология эше буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат  муниципаль  районы
Әмзә авыл җирлеге
Советы Рәисе                                                                А.Ә. Насыйбуллин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июленләге 20 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләр кисү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләр кисү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәнең гамәлдә булуы түбәндәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибенә кагылмый:

Россия Федерациясе дәүләт урман фонды;

физик һәм юридик затларның шәхси милкендә булган.

## 2. Төп төшенчәләр

2.1. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшел үсентеләр - табигый һәм ясалма килеп чыккан агач, куаклыклар һәм үлән төрендәге үсемлекләр (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәк түтәлләрен, шулай ук аерым торучы агачларны һәм куакларны да кертеп);

табигый территорияләр-бердәм географик (климатик) шартларда формалашкан җир рельефының, туфракның, үсемлекләрнең билгеле бер төрләрен үз эченә алган хуҗалык эшчәнлеге белән кагылмаган яисә аз кагылган территорияләр;

Яшелләндерелгән территорияләр - табигый барлыкка килгән үсемлекләр участоклары, ясалма яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең 50 процентан да ким булмаган өлеше үсемлекләр капламы белән капланган аз төзелгән участоклар;

Урман каплап алган территорияләр– табигый рәвештә үсеп чыккан урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләр участоклары;

агач – 1.3 м биеклектә диаметры 5 см дан да ким булмаган кәүсәсе ачык беленеп торган үсемлек, үсентеләрдән кала;

зарарланган агач – бу барлык агачның яисә аның өлешенең җимерелүенә, кешеләргә, транспорт чараларына, инженерлык инфраструктурасының зарарлануына (шул исәптән электр тапшырулары, газүткәргечләр, җылылык трассалары һ.б.лар), биналарның һәм корылмаларның җимерелүенә китерергә сәләтле структур җитешсезлекләр булган агач, шулай ук агач үсү яисә яшь чигенә җиткән агач, шулай ук түбәндәге билгеләре булган агачлар да авария хәлендә дип билгеләнергә мөмкин: корыгын ботаклары булган яисә кәүсәсе корый башлаган агачлар, көпшәсе куыш яки ярык булган, үзагачы черегән агачлар, кәүсәсе (кәүсә калынлыгыннан 1/3) скелет ботаклары, тамырлары тирән зыянланган, кәүсәсенең авыш почмагы тигез һәм 15 градустан артык, агач гөмбәләре яки бөҗәк-корткычлар белән зарарланган, объектларның инженерлык коммуникацияләре саклау зоналарында үсә торган агачлар;

куак – туфракның иң өске катламында тармакланучы күпьеллык күп ботаклы (агачтан аермалы буларак);

үлән катламы – газон, табигый үлән катламы;

куе агачлыклар – нинди дә булса урында үсүче үсемлекләр, куаклар;

яшел массив – бердәм тоташ чатыр хасил итүче яшь булмаган (15яшьтән өлкәнрәк) агачларның 50дән артык нөсхәсе үсә торган территория участогы.

Яшел үсентеләргә зыян китерү - аларның үсешен туктату, шул исәптән ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, тамырның бөтенлеген, тере туфрак катламын бозу, яшел үсентеләрне яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка йогынты ясау;

Яшел үсентеләрне юк итү - яшел үсентеләрне кисү яки башка зыян китерү, аларның үсешен туктату;

Компенсацион яшелләндерү - юк ителгән яки зарарланган 2 коэффициенты белән яшел утыртмаларны яңадан булдыру.

## 3. Яшел үсентеләрне саклауның төп принциплары

3.1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба – Әмзә авыл җирлеге) үсә торган яшел үсентеләр саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкаралар һәм сакланырга тиеш.

3.2. Әмзә авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.

3.3. Әмзә авыл җирлеге территориясендә оешмаларның җитәкчеләренә үзләре белдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә яшел утыртмаларның сакланышын һәм үсешен тәэмин итү буенча бурычлар йөкләнә.

3.4. Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләрен кулланучылар һәм арендаторлар яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел үсентеләрне тиешле тәртиптә карарга тиешләр.

3.5. Әмзә авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

3.6. Җир участогын сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документларында яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулы бәяләү булырга тиеш.

3.7. Яшел утыртмаларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итүгә туры килми торган яшелләндерелгән территорияләрдән һәм яшел массивлардан файдалану рөхсәт ителми.

## 4. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

4.1 Әмзә авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү тыела.

4.2. Әмзә авыл җирлеге территориясендә агач һәм куакларны кисү комиссия тикшерүе акты нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган рөхсәт нигезендә башкарыла.

4.3. Рөхсәт бирү мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлары булмаган очракта (авария хәлендәге һәм гадәттән тыш хәлләргә һәм авария хәлендәге агачларны кисү очракларыннан тыш) белешмәләр булганда гамәлгә ашырыла.

4.4. Яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә хат-гариза бирә, анда утыртмаларның саны, исеме, аларның торышы, чикләнгән кисү үткәрү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелергә тиеш. Гаризага

(авария хәлендәге һәм гадәттән тыш хәлләргә һәм авария хәлендәге агачларны кисүгә бәйле очраклардан тыш) түбәндәге документлар өстәлеп бирелә:

4.4.1. Шәхесне раслаучы документлар йә вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәлдә булса);

4.4.2. Кисәргә тиешле яшел үсентеләрне төшерү белән якындагы корылмаларга яки башка юнәлешләргә кадәр җир кишәрлеге схемасы;

4.4.3. Җир кишәрлеге Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, гариза бирүче тарафыннан расланган җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәләре:

4.4.4. Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел үсентеләр киселгән очракта, расланган проект документлары;

4.4.5. Яшел үсентеләрне кисү һәм утырту шартлары хуҗалары белән килешү;

4.4.6. Үсентеләрне утыртканда яки күчереп утыртканда инженерлык челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен башкаруга ордер ачу белән килешү.

4.5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башкарма комитеты хат – гариза (гадәттән тыш хәлләр һәм авария хәлендәге агачлар кисүгә бәйле очраклардан тыш) килгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә әлеге төр эшләрне башкаруга рөхсәт алган махсус оешмага мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә:

яшел утыртмаларның исәп-хисап исемлеге;

агач-куак кисәргә тиешле агач утыртмаларының санын, төрен, категориясен билгеләү максатларында төзелә торган яшел үсентеләрне натураль тикшерү акты;

киселгән агач өчен түләүне (түләүне) исәпләү, киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.

Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару гариза бирүче хисабына башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы-90 көн.

4.6. Эшләр башкаруга рөхсәт алган очракта (мөрәҗәгать итүче (авария һәм гадәттән тыш хәлләр һәм авария хәлендәге агачлар кисүгә бәйле очраклардан тыш), аның мәнфәгатьләрендә яшел үсентеләр юкка чыгарыла торган очраклардан тыш), әлеге Нигезләмә нигезендә яшел үсентеләрне кискән өчен түләүләрне кертергә һәм компенсация яшелләндерүне киләчәктә дә үткәрүне раслаучы гарантия хаты бирергә тиеш.

Агач һәм куак кискән өчен түләү гариза бирүче тарафыннан җирле бюджетка күчерелә.

4.7. Яшел үсентеләрне кисү эшләре билгеләнгән нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китереп, гариза бирүче акчасы хисабына башкарыла. Агач кисәргә урман аударучы белгечлеге буенча белем алган яки тиешле күнекмәләре булган затларга гына рөхсәт ителә.

4.8. Аударган, түмгәге казып алынган яшел агачларны һәм калган ботакларны төяү һәм алып китү эшләр башланган вакыттан алып өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүче исәбеннән башкарыла. Киселгән яшел утыртмаларны һәм эшләр урынында киселгән агач ботакларын калдыкларны саклау тыела.

4.9. Территориянең кисү урынына якын урнашкан территориядә газ, яшел үсентеләр зарарланган очракта, эшләр җитештерүче аларны территориянең хуҗасы һәм контроль органнары белән алар компетенциясе чикләрендә килештерелгән, әмма зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, аларны мәҗбүри рәвештә торгызу эшләрен башкара.

4.10. Агачны кискән өчен түләүне гамәлгә ашырмыйча агач һәм куакларны кисү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

Сирәкләү максатыннан агачларны кисү, санитар кисүләр һәм яшел үсентеләр үскән урынны төзекләндерү;

авария хәлендәге һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

Роспотребнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм иҗтимагый биналарда ут режимын боза торган агач һәм куакларны кисү;

Авария хәлендәге (төшү куркынычы тудыручы, корыган агачларны) һәм куакларны кисү.

Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләр кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә әлеге Нигезләмәнең 4.4.1 – 4.4.6 пунктында күрсәтелгән документларны хат – гаризага теркәп куярга һәм компенсацион яшелләндерүне үткәрергә кирәк түгел.

4.11. Яшел үсентеләрне санкциясез кисү яки юк итү дип түбәндәгеләр танылa:

рөхсәтсез яки рөхсәт белән рөхсәттә күрсәтелгән участокта түгел, күрсәтелгән күләмдә түгел, күрсәтелгән агач төрләрен түгел, башка агач һәм куакларны кисү;

ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агач һәм куакларны юк итү яки зыян китерү;

агач ябалдашын түгәрәкләп кисү, кыскарту;

үсә торган агачларның һәм куакларның үсүе туктатылганчыга кадәр зарарлануы;

агач һәм куакларның юынтык сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башкалар белән зарарлануы;

корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

үсә торган агачларның һәм куакларның башка төрле зарарланулары.

## 5. Компенсацион яшелләндерү

5.1. Компенсацион яшелләндерү рөхсәт ителгән кисүләр, яшел үсентеләрне законсыз зарарлау яки юкка чыгару очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсацион яшелләндерү якындагы сезонда, агачлар, куаклар һәм газлар утырту өчен яраклы, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару факты билгеләнгән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

5.2. Компенсацион яшелләндерү гражданнарның яисә юридик затларның мәнфәгатьләрендә яисә хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел утыртмаларга зыян килгән яисә юкка чыгарылган гражданнарның яки юридик затларның акчалары исәбеннән башкарыла.

5.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян натураль формада - компенсация яшелләндерүенә: 2 коэффициенты белән юкка чыгарылган яшел үсентеләрне яңадан торгызуга түләнергә тиеш.

## 6. Җирлектә инфраструктура төзелеше эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

6.1. Әмзә авыл җирлегендә инфраструктура төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәү белән алып барыла.

6.2. Яшелләндерелгән территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир участоклары, аларның максатчан билгеләнеше белән бәйле булмаган төзелештә кулланылырга тиеш түгел.

6.3. Яшел үсентеләр биләгән җир кишәрлекләрендә төзелешне оештырганда, проект документларында киселергә тиешле яшел үсентеләрне бәяләү булырга тиеш. Бу очракларда зыянны каплау әлеге Нигезләмәнең 4 һәм 5 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә агач киселгән өчен түләүне алдан кертү һәм компенсация рәвешендәге яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 7. Эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда яшел үсентеләрне саклау

7.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлеге, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы

Әмзә авыл җирлеге башкарма комитеты рөхсәтеннән башка эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

7.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда, яшел территорияләрдә һәм яшел массивларда шартлаткыч, утлы һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, үз артыннан яшел үсентеләргә зыян китерергә яки юк итәргә сәләтле башка гамәлләр тыела.

## 8. Җаваплылык

8.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап тота.